**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кармалка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кармалка авыл җирлегенең Чумачка торак пунктында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре**
**турында**

**17 октябрь 2025 ел** **№ 1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 17 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Түбән Кармалка авыл җирлегенең Чумачка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1400 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (Чумачка торак пунктында юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, ЩПС сатып алу, ротацияле асма чапкыч сатып алу, проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Чумачка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су җыю манараларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, Чумачка торак пунктындагы артезиан скважинасы

территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү);

**- киртәләр ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, чүп савытлары кую, агач кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү, Чумачка торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 84 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 45 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 45 кеше тавыш бирде, «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең Чумачка торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Түбән Кармалка авыл җирлегенең Чумачка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1400 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (Чумачка торак пунктында юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, ЩПС сатып алу, ротацияле асма чапкыч сатып алу, проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

**- электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Чумачка торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);

**- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су җыю манараларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, Чумачка торак пунктындагы артезиан скважинасы

территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү);

- **киртәләр ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, чүп савытлары кую, агач кисү, корысарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү, Чумачка торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү) **кабул ителгән дип танырга.**

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы А.Ф. Митякин